**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрүне камилләштерү максатларында, шулай ук кайбер затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-79 номерлы Указына (Татарстан Республикасы

Президентының 2014 елның 15 февралендәге ПУ-166 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1161 номерлы, 2015 елның 28 маендагы ПУ-497 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1226 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-458 номерлы һәм 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның унынчы абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:»;

в) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибендә:

5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

г) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, төбәк дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясе (алга таба – эксперт комиссиясе) составында:

эксперт комиссиясе составыннан Р.Ю. Беляковны, М.Р. Зариповны, Н.А. Таркаеваны, И.Ә. Фәйзуллинны, А.А. Фоминны, А.К. Хамаевны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

эксперт комиссиясе составына кертергә:

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Груничев Александр Станиславовичны – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисен;

Кондратова Наталья Владимировнаны – Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын, аны эксперт комиссиясе секретаре итеп раслап;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Хисамиев Марат Рамил улын – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 31 гыйнвар
№ ПУ-55